КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 11 декабрь г.Казань № 973

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 июль, 502 нче; 2017 ел, 31 март, 203 нче; 2017 ел, 24 октябрь, 807 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Юридик затларга – норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсында җиңүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе.»;

әлеге карарга Юридик затларга – норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсында җиңүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен өстәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 14 декабрь, 943 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 11 декабрь, 973 нче
карары редакциясендә)

Юридик затларга – норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсында җиңүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнгән һәм Юридик затларга – норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсында (алга таба – конкурс) җиңүчеләргә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр агымдагы елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында нигезләмә нигезендә җиңүчеләр һәм призерлар дип танылган юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) (алга таба – субсидия алучылар) аларның устав (гамәлгә кую) документларында каралган максатларга, шул исәптән норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрүдә катнашкан затларны бүләкләүгә бирелә.

3. Субсидияләр бирүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш идарә итүче булып Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тора (алга таба – баш идарә итүче).

4. Субсидияләр әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Респуб-ликасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасы белән каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы чикләрендә бирелә.

5. Субсидия алучы субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырылган айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә җавап биргән шартларда субсидия бирелә:

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (оффшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик заты түгел;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормый.

6. Субсидия Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча экспертларның ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында нигезләмәнең 3.11 пункты нигезендә түбәндәге күләмнәрдә бирелә:

конкурс җиңүчесе дип танылган субсидия алучыга – 100,0 мең сум;

икенче урынны алган конкурс призеры дип танылган субсидия алучыга – 80,0 мең сум;

өченче урынны алган конкурс призеры дип танылган субсидия алучыга – 70,0 мең сум.

7. Субсидия алу өчен субсидия алучылар агымдагы елның 15 декабреннән соңга калмыйча баш идарә итүчегә юридик затны дәүләт теркәвенә алу, салым органында исәпкә кую мәгълүматларын, субсидия күчерү өчен түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидия бирү турында гариза тапшыралар, анда түбәндәге мәгълүматлар була:

субсидия алучы чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (оффшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик заты түгел;

субсидия алучы әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормый.

8. Баш идарә итүче субсидия бирү турында гаризаны алган көнендә теркәүне гамәлгә ашыра.

9. Баш идарә итүче субсидия бирү турында гаризаны теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

10. Субсидия бирүдән баш тартылган очракта баш идарә итүче карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә субсидия алучыга тиешле хәбәрнамә җибәрә.

11. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләр:

юридик затның әлеге Тәртипнең 2 һәм 2 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

документларны тулы күләмдә тапшырмау яки аларның әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве;

субсидия алучы тапшырган мәгълүматның дөрес булмавы.

12. Субсидия Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы раслаган үрнәк форма нигезендә баш идарә итүче белән субсидия алучы арасында субсидия бирү турында килешү нигезендә бирелә һәм субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң унынчы эш көненнән соңга калмый субсидия бирү турында гаризада күрсәтелгән россия кредит оешмасында субсидия алучыга ачылган исәп-хисап счетына яки корреспондент счетына күчерә.

Килешүдә субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидиядән файдалану турында хисап бирү тәртибе, формасы һәм вакытлары, баш идарә итүче, дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләрне гамәлгә ашыруг субсидия алучының ризалыгы (субсидия алучы дәүләт (муниципаль) унитар предприятие, устав (тупланма) капиталларында гавәми-хокукый берләшмәләр катнашында хуҗалык иптәшлеге һәм җәмгыяте, шулай ук устав (тупланма) капиталларында мондый хуҗалык иптәшлекләре һәм җәмгыятьләре катнашында коммерциячел оешмалар булган очраклардан тыш), субсидия алучының әлеге Тәртип һәм төзелә торган шартнамә шартларын үтәүе турында нигезләмәләр карала.

13. Бирелгән субсидияләр әлеге Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү тәртибе һәм шартлары бозылу фактлары билгеле булган очракта баш идарә итүченең тиешле таләбен алган көннән соң 30 көн эчендә бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидия алучы субсидияне кире кайтару вакытларын бозганда баш эш итүче субсидияне кире кайтару вакыты узган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә әлеге акчаны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кайтару буенча чаралар күрә.

14. Субсидия алучы субсидиядән файдалану турында баш идарә итүчегә шартнамәдә каралган формада, вакытларда һәм тәртиптә хисап тапшыра.

15. Баш идарә итүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлүен тикшерүне законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

______________________________